ӘЙДӘ, ХАЛЫККА ХЕЗМӘТКӘ, ХЕЗМӘТ ЭЧЕНДӘ ЙӨЗМӘККӘ!

# САБА ТАҢНАРЫ

8 февраль
Җомга,
2019 ел
№9 (10305)

ГАЗЕТА 1930 ЕЛНЫҢ 25 НОЯБРЕННӘН ЧЫГА

saba-tannary@tatmedia.com

САБИНСКИЕ ЗОРИ

saby-rt.ru

ИГЪТИБАР: ЯҢА КОНКУРС

## «АДӘМ БЕЛӘН ҺАВА»

*Хөрмәтле абунәчеләребез! Алда көтелгән куелды. Әлеге парларның барысының да исемнәрен дөрес итеп беренчеләрдән булып җиткерүчеләргә*




җитеп, үсеш 105 процент булган. "Быел 6800 литрга җиткерүне планлаштырабыз",– диде белгеч һәм терлек авыруларын булдырмау максатында күрелгән чаралар турында сөйләде. Шулай ук көтүне яхшыртуның яңа технологиясе турында да әйтеп узды. Сүз аз продуктлы сыерның аналыгына күп сөт биргәненең эмбрионын күчереп утырту турында бара. Нәтиҗәдә кертелгән сыерларның аналыгында үскәннәре дә аның генетик үзлегенә ия була. Яңа технологияне кер-

**"Курсабаш" җәмгыятендә уртача 100 кеше эшләгән. Уртача хезмәт хакы 23010 сум (2017 елда – 21544 сум) тәшкил иткән.**

базасы булып игенчелек тармагы кала. Былтыр "Курсабаш"та бер гектардан 21 центнер гына ашлык уңышы алынган. Моның кайбер сәбәпләрен агроном Фәрит Фәсхиев үзенең чыгышында әйтте. Чәчү әйләнеше үтәлмәгән, тиешле срокларда дым тиешле срокларда каплатылмаган, техника җитмәгәнлектән язгы чәчүне вакытында тәмамлый га, ялгышларны бергәләп төзәтергә кирәк",– диде агроном. Икътисадчы Фәнил Габдерахманов быел ашлыкны 35900 центнер җитештерү (2018 елда – 28742 ц.) бурычын куйды. Сөт алуны –5, сыерларны гамәлдән чыгаруны 9 процентка киметүне, бозауларның тәүлеклек артымын 850 граммга җиткерүне планлаштыралар.

*(Ахыры 2нче биттә).*

## Рейтингыңны беләсең килсә

Саба муниципаль районы башкарма комитеты 2018 ел йомгаклары буенча районның иҗтимагый советы тарафыннан мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар һәм мәдәният учреждениеләре күрсәткән хезмәтнең сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрелүе турында хәбәр итә. Бәяләү йомгаклары белән район сайтына түбәндәге сылтама аша кереп танышырга була: http://saby.tatarstan.ru/rus/reytingi-organizatsiy.htm

АБУНӘ-2019

## *Алдан язылган – откан*



*Хөрмәтле укучыларыбыз! 1 февральдән "Саба таңнары" газетасына ташлама белән вакытыннан алда язылу кампаниясе башланды. Ягъни 1 апрельгә кадәр районыбыз матбугатына 699 сумнан абунә рәсмиләштереп калу мөмкинлеге булачак. Аннан соң бәяләр артып куюы да бар. Шуңа күрә газета укучыларыбызны әлеге мөмкинлектән файдаланып калырга чакырабыз. "Саба таңнары"на тугры сабалылар булып калыйк!*

КИЧӘ. БҮГЕН. ИРТӘГӘ.

## Нияз – Бөтенроссия бәйгесе батыры

Зәйдә районның элеккеге башлыгы Ринат Фәрдиев истәлегенә Бөтенроссиядагы трассада оештырыла. Спорт залында катнашучыларны теркәү 9 сәгатьтә башлана. Ярышка теләгән һәм табиб рөхсәте булган һәркем кертелә. Ачылыш тантанасы һәм трасса белән танышу 10.40-11.00 сәгатьләрдә була. Аннары старт-ка мәктәпкәчә яшьтәгеләр 200 метрга узышу өчен баса. 11.10-11.30 сәгатьләрдә укучыларга старт бирелә. Ир-егетләр һәм хатын-кызлар барысы бергә 11.40 сәгатьтә китә. VIP старт – 11.50 сәгатьтә. Беренче-өченче урын алучыларны Грамота, акчалата призлар көтә, ә мәктәпкәчә яшьтәгеләр барысы да бүләкләнәчәк. Әлеге спорт чарасына төрле яшьтәге районнашларыбызны көтеп калалар.

**ҺАВА ТОРЫШЫ**

**9 февраль**

| | |
|---|---|
| Көндез | -6 градус |
| Төнлә | -5 градус |

**10 февраль**

| | |
|---|---|
| Көндез | -6 градус |
| Төнлә | -9 градус |

*Доллар – 66,08*

*Евро – 74,90*